**Планлаштырылган нәтиҗәләр**

**Предмет нәтиҗәләре**

**1 класс**

**<u>Укучы өйрәнә</u>**

Фольклор әсәрләрне аера белә (табышмак, санамыш, тизәйткеч, әндәшләр һ.б); әсәрләрнең авторы юк икәнлеген белә.

Әсәрнең темасын билгели, укытучы ярдәмендә укылган әсәрнең төп уен билгели белә, әсәрнең төп героен, әсәрдәге вакыйгаларны аера белә,әсәр буенча сорауларга җавап бирә белә, рәсемле планга, яки иллюстрациягә таянып, әсәрнең эчтәлеген сөйли ала, әдәби әсәрнең исемен, авторын әйтә белә.

Хикәянең төп геройларын атый ала, әсәрдәге геройларга карата үз фикерен белдерә белә, әсәрнең темасын билгели, укытучы ярдәмендә укылган әсәрнең төп уен билгели белә, әсәрдәге вакыйгаларны аера,әсәр буенча сорауларга җавап бирә белә, рәсемле планга, яки иллюстрациягә таянып, әсәрнең эчтәлеген сөйли ала.

Проза һәм шигъри әсәрләрне аера белә,  рифма, кабатлауларны таба ала.

Эчтәлек битеннән кереш әсәрнең кайсы биттә булуын ачыклый ала,китапханәдән алган китапның авторын,исемен, темасын билгели белә.

Әсәрне иҗекләп, аерым сүзләрне дөрес әйтеп укый белә, укыганда орфоэпия нормаларын төгәл саклый.

**<u>Укучы өйрәнү мөмкинлеге алачак</u>**

Әйләнмәле һәм чылбыр әкиятләрне аерырга, әсәрнең төп уен үзаллы билгеләргә,укытучы ярдәмендә төзелгән план нигезендә, әсәрнең эчтәлеген сөйләргә,укылган әсәр нигезендә тексттан чагыштырулар, әндәшләр табарга, тексттан геройлар арасындагы диалогны табып укырга, укылган әсәрнең аерым эпизодларына рәсем ясый алырга.

Сурәтләнгән вакыйгаларга карата автор фикерен билгеләргә.

Ике образны чагыштырып сөйләргә.

Әсәрдән рифманы табарга, куллана белергә,шигырьне сәнгатьле укырга өйрәнергә.

Бирелгән китапны китапханәдән табарга,темасы, авторы, исеме буенча дәреслектән тиешле әсәрне табарга,рәсеме һәм тышлыгы буенча китапның якынча темасын билгеләргә.

Дөрес тавыш төсмерләре(тавыш көче, темпы) белән укырга.

**2 класс <u>Укучы</u>**

**<u>өйрәнә</u>**

Халык иҗаты һәм автор әсәрләре турында күзаллау булдырып, халык әсәрләрен автор әсәрләреннән аера белергә, үз фикеренне белдерү өчен, кыска монологлар төзергә, укытучы сорауларына тулы җавап бирергә.

2-3 татар, 1-2 рус классик язучысынын исемен әйтергә.Үзеннең яраткан авторын турында, аның әсәрләре турында сөйли белергә.Бирелгән текстның темасын, төп мәгънәсен ачыкларга.Аңлашылмаган сүзләрнен мәгънәләрен ―Аңлатмалы сүзлектән‖ карага.Әсәр геройларына характеристика бирергә.Тылсымлы әкиятләрне хайваннар әкиятеннән аерырга, тылсымлы әкиятләрнең үзенчәлеген ачыкларга.

Әкият һәм хикәяне аерырга. Әсәрдә сүрәтләү чараларын табарга ( чагыштыру, капма-каршылык, кабатлау, җанландыру).

Д̆ереслектӗ җиңел генӗ ориентлашырга.Д̆ереслектӗ танышкан ӗсернӗң кайсы язучының икӗнен, алар язган башка ӗсерлӗрне ӗйтергӗ, эчтӗлеген сө̆йлӗргӗ.2-3 балалар газетасы яки журналы турында сө̆йли белергӗ.Ә̆сӗр геройларына характеристика бирергӗ. Китапханӗдӗн укытучы тӗкъдим иткӗн китапны эзлӗп табарга.Ә̆сӗрлӗр буенча инценировкалар ӗзерлӗргӗ.
Укуның тө̆рле формаларыннан файдаланырга: эчтӗн, кычкырып, сайлап, рольлӗргӗ бүлеп укырга.Текст белӗн танышканда эчтӗн беренчел укып чыгарга, кыска һӗм тулысынча сө̆йли белергӗ.Үз фикереңне ӗйтӗ белергӗ,укылганның эчтӗлеген аңлап, интонация белӗн, уку темпын сайларга, паузалар белӗн укырга.Программада каралган текстларны аңлап укырга һӗм эчтӗлеген сө̆йлӗргӗ.
**<u>Укучы өйрәнү мөмкинлеге алачак</u>**
Укытучы укыган текстны аңлап, үз фикерен белдерергӗ. ―Серле ачкыч‖ мӗктӗбе клубына хат язарга.Укыган ӗсӗргӗ үз фикерен белдерергӗ. Тө̆рле авторның 6-8 шигырен яттан укый алырга. Китапханӗдӗн китаплар сайлаганда, кирӗкле ӗсӗрне ―Эчтӗлек‖ битеннӗн эзли белергӗ. Теманы ө̆йрӗнгӗндӗ охшаш текстларны, бер үк автор ӗсӗрлӗрен д̆ереслекнең икенче кисӗгеннӗн таба алырга.Укылган текстлардан ө̆земтӗлӗр китереп, сорауларга җавап бирергӗ.Автор ӗсӗрлӗрендӗ фольклор элементларының чагылышын, ӗкиятлӗрнең сюжет-композиция үзенчӗлеклӗрен ачыкларга .Ә̆дӗби-ӗсӗрлӗр белӗн фольклор арасындагы чикнең сыгылмалыгын билгелӗргӗ.Табигатьтне шагыйрь күзлегеннӗн карап таный белергӗ.Шигъри һӗм проза ӗсӗрлӗрен сӗнгатьле укып чыгып, текстка карата үз мӗнӗсӗбӗтең не белдерергӗ.
Язучыларның иҗат биографиялӗре белӗн танышырга.
**3 класс <u>Укучы</u>**
**<u>өйрәнә</u>**
Халык авыз иҗатының гасырлар д̆евамында үсешен , булган тормыш тӗҗрибӗсен ӗкиятлӗрнең тӗрбияви ролен кабул итеп ала , мӗкальлӗрне , мӗсӗллӗрне сө̆йлӗмдӗ урынлы куллана белӗ.
Сүзлӗрнең синонимнарын табарга, сүзнең туры һӗм контексттагы мӗгънӗсен аңлый ;ӗсӗрлӗргӗ анализ ясаганда, ө̆йрӗнелгӗн ӗдӗби тө̆шенчӗлӗрне кулланырга;геройларның монологик сө̆йлӗмен, диалогларны табып укырга.
Хикӗя геройлары , аларның портреты һӗм характер үзенчӗлеклӗренең башкарган гамӗллӗре аша ӗсӗрлӗрнең геройларына характеристика бирӗ, ӗсӗр геройларына карата үз фикерен белдерӗ белӗ..
Д̆ө̆ньяны шагыйрьлӗр күзлегеннӗн чыгып күзаллый, шигырьлӗрдӗ эпитет, чагыштыру, сынландыруны, җанландыруны таба белӗ,темп, тавыш кө̆че, тон, сө̆йлӗм мелодикасын үзлӗштӗрӗ.Балалар китабы, фӗн буенча сүзлек, белешмӗ ӗдӗбият, вакытлы матбугат белӗн эшли.,ө̆й, мӗктӗп китапханӗлӗреннӗн файдалана белӗ, бирелгӗн темага тө̆рле җыентыклар тө̆зи белӗ.Интонация, тон, темп саклап кычкырып аңлап укый. Эчтӗн,чылбыр рӗвешендӗ үз урынын белеп, чират буенча укый.Укыган ӗсӗргӗ анализ ясый.
**<u>Укучы өйрәнү мөмкинлеге алачак</u>**
Тылсымлы һӗм хайваннар турындагы ӗкиятлӗрне аера белергӗ, мӗкальлӗрне тө̆рле ситуациялӗрдӗ урынлы куллана , укылган ӗсӗрнең ӗхлакый эчтӗлеген аңлый гомумкулланышта булган ӗхлакый нормаларга таянып, геройларның эш-гамӗллӗренӗ бӗя бирергӗ, үз фикерен белдерергӗ; автор позициясен аңлата, автор фикере белӗн килешү- килешмӗвен д̆елилли белергӗ.
Үзлегеңнӗн синонимнарны табарга, сүзнең туры һӗм контексттагы мӗгънӗсен аңлый ,ӗсӗрлӗргӗ анализ ясаганда, ө̆йрӗнелгӗн ӗдӗби тө̆шенчӗлӗрне кулланырга, геройларның монологик сө̆йлӗмен, диалогларны табып укырга.

Өйрәнелә торган әсәрләргә иллюстрацияләр ясый белергә , әсәрнең аерым эпизодларына сүзле сурәт ―ясарга‖- темалар буенча, ―Халык һәм автор әкиятләре‖ темасына кумәк яки шәхси проектлар эшли белергә. Проза әсәрләрен өлешләргә бүлә белергә, аларга исем кушу (план төзү), план буенча эчтәлек сөйли белергә. Бүлектән авторларның исем фамилияләрен истә калдыра,табигать, җенлекләр, кошлар турында яңа мәгълүматлар туплый белергә.

Дәреслектән һәм белешмәлекләрдән кирәкле мәгълүматны мөстәкыйль таба белергә. Китапның авторы турында мәгълүмат таба белергә, фәнни-популяр әсәр текстыннан һәм белешмәлекләрдән предмет, күренеш турында мәгълүмат туплый белергә. Текстта булган мәгълүматны мәгълүмати чыганаклар белән чагыштыра белергә,модельләре буенча әсәрләрне чагыштырыра, тулыландырыра, төзәтә, ачыклый белергә. Укучы әдәби әсәрдән автор җиткерергә теләгән төп фикерне аерып чыгара белергә, шулай ук аның лирик әсәрнең хис белдерү өчен хезмәт итүен аңларга, әсәрдә автор һәм анда катнашучы геройларның фикер аерымлыкларын күрә, күрәтә белергә.

**4 класс**

**<u>Укучы өйрәнә</u>**

Халык иҗаты һәм автор әсәрләре турында күзаллау булдырып, халык әсәрләрен автор әсәрләреннән аера белергә, үз фикеренне белдерү өчен, кыска монологлар төзергә, укытучы сорауларына тулы җавап бирергә.
2-3 татар, 1-2 рус классик язучысынын исемен әйтергә.Үзеннең яраткан авторын турында, аның әсәрләре турында сөйли белергә.Бирелгән текстның темасын, төп мәгънәсен ачыкларга.Аңлашылмаган сүзләрнен мәгънәләрен ―Аңлатмалы сүзлектән‖ карага.Әсәр геройларына характеристика бирергә.Тылсымлы әкиятләрне хайваннар әкиятеннән аерырга, тылсымлы әкиятләрнең үзенчәлеген ачыкларга.
Әкият һәм хикәяне аерырга. Әсәрдә сүрәтләү чараларын табарга ( чагыштыру, капма-каршылык, кабатлау, җанландыру).
Дәреслектә җиңел генә ориентлашырга.Дәреслектә танышкан әсәрнең кайсы язучының икәнен, алар язган башка әсәрләрне әйтергә, эчтәлеген сөйләргә.2-3 балалар газетасы яки журналы турында сөйли белергә.Әсәр геройларына характеристика бирергә. Китапханәдән укытучы тәкъдим иткән китапны эзләп табарга.Әсәрләр буенча инценировкалар әзерләргә.
Укуның төрле формаларыннан файдаланырга: эчтән, кычкырып, сайлап, рольләргә бүлеп укырга.Текст белән танышканда эчтән беренчел укып чыгарга, кыска һәм тулысынча сөйли белергә.Үз фикереңне әйтә белергә,укылганның эчтәлеген аңлап, интонация белән, уку темпын сайларга, паузалар белән укырга.Программада каралган текстларны аңлап укырга һәм эчтәлеген сөйләргә.

**<u>Укучы өйрәнү мөмкинлеге алачак</u>**

Укытучы укыган текстны аңлап, үз фикереңне белдерергә.Мифлар, төрле халыкларның әкиятләрендә аларның бирелешен өйрәнергә.Төрле халыклар әкиятендә географик атамаларның бирелешен ачыкларга. Автор әсәрләрендә фольклор элементларының чагылышын, әкиятләрнең сюжет-композиция үзенчәлекләрен ачыкларга .Әдәби-әсәрләр белән фольклор арасындагы чикнең сыгылмалыгын билгеләргә.Табигатьтне шагыйрь күзлегеннән карап таный белергә.Шигъри һәм проза әсәрләрен сәнгатьле укып чыгып, текстка карата үз мөнәсәбәтеңне белдерергә. Язучыларның иҗат биографияләре белән танышырга.

**Метапредмет нәтиҗәләре.**

**Регулятив универсаль уку гамәлләре.**

1.Мҿстҽкыйль рҽвештҽ дҽреснең проблемасын (тема) һҽм максатларын формалаштыру.
2.Максатка ирешү юлларын билгелҽү.
3.Укытучы җитҽкчелегендҽ эш урынын ҽзерлҽү, оештыру.
2.Укытучы җитҽкчелегендҽ дҽрестҽ, дҽрестҽн тыш эшчҽнлектҽ, тормыш ситуациялҽрендҽ биремнҽрне үтҽү максатын билгелҽү.
3.Укытучы җитҽкчелегендҽ дҽрестҽ, дҽрестҽн тыш эшчҽнлектҽ, тормыш ситуациялҽрендҽ биремнҽрне үтҽү планын билгелҽү.

**Танып-белү универсаль уку гамәлләре.**

1.Укучының үз эшчүнлегген мҿстҽкыйль рҽвештҽ оештыра белү,бҽялҽү, үзенең кызыксынучанлык ҿлкҽсен билгелҽү.
2.Мҿстҽкыйль рҽвештҽ тҿрле текстларны укый белү, ҿстҽмҽ материаллардан таба белү.
3.Тҿрле мҽгълүмат чаралары белҽн эшли, кирҽкле мҽгълүматны таба,анализлый һҽм үз эшчҽнлегендҽ куллана белү.
4.Бер мҽгълүматны икенче тҿрле итеп үзгҽртҽ алу.
5.Ҽдҽбиятны музыка һҽм рҽсем сҽнгате белҽн бҽйлҽп, сүз сҽнгатенең кыйммҽтен күрсҽтү, матурлыкны таныргa ҿйрҽтү.
6.Татар ҽдҽбиятын рус ҽдҽбияты, башка халыклар ҽдҽбияты белҽн бҽйлҽп укытып, ҽдҽбиятлар арасындагы уртак проблемаларны, уртак кыйммҽтлҽрне күрсҽтү аша, дҿнья культурасы белҽн танышу.

**Коммуникатив универсаль уку гамәлләре.**

1.Дҽрестҽ һҽм тормыш ситуациялҽрендҽ диалогта катнашу.
2.Тҿрле фикерлҽрне исҽпкҽ алып эш итү.
3.Үз фикереңне дҽлилли белү.
4.Тҿрле җавапларны тыңлау , чагыштыру, нҽтиҗҽ ясау.
5.Укытучы, сыйныфташларның сорауларына җавап бирү.
6.Башкаларның сҿйлҽмен тыңлап аңлау.
7. Парлап, кечкенҽ тҿркемнҽрдҽ һҽм күмҽк эшлҽү
8.Иптҽшлҽрең каршында тҿрле темага чыгыш ясау.

**Шәхескә кагылышлы универсаль уку гамәлләре.**

1. Туган республикага, туган илгҽ, халкына, ил тарихына карата гражданлык нигезлҽре, үз миллҽтен ярату, татар булуы белҽн горурлану хислҽре формалаштыру.
2. Табигать, халык, культура, дин тҿрлелеген берлҽштергҽн дҿньяга социаль караш формалаштыру.
3. Башка халыкларның культурасына, тарихына хҿрмҽтле караш, башкалар фикеренҽ карата түземлелек формалаштыру.
4. Укучының тоткан урынын, укучы ролен кабул итү, укуга карата кызыксыну уяту, укуның шҽхсҽн мҽгънҽсен аңлауны формалаштыру.
5. Ҽхлакый нормаларны кузаллауга нигезлҽнеп, укучының үз эшлҽгҽн эшлҽре ҿчен шҽхси җаваплылыгын, мҿстҽкыйльлеген үстерү.
6. Эстетик ихтыяҗ һҽм хис формалаштыру.
7. Башкалар хисен аңлау, кайгыртa белү, шҽфкатьлелек, мҽрхҽмҽтлелек, ҽхлакый хислҽрен үстерү.

8. Балаларның дуслары, олылар белән хезмәттәшлек итү күнекмәләрен формалаштыру, конфликтлы ситуацияләрне булдырмау һәм алардан чыгу юлларын таба белүләрен үстерү;
9. Куркынычсыз һәм сәламәт яшәү рәвеше формалаштыру, төрле тормыш ситуацияләренә һәм әдәби әсәрләрдәге геройларның гамәлләренә кешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү.
10. Иҗади хезмәткә, эшнең нәтиҗәсенә мотивация булдыру, материаль һәм рухи байлыкларга сак караш формалаштыру.

## Предметның эчтәлеге

### 1 нче сыйныф

### Әзерлек чоры

Әкият текстын тыңлау. Иллюстрациялорнең (рәсемнәрнең) текст өлешләре белән бәйләнешен (мәнәсәбәтен) ачыклау. Әкият эчтәлеген сөйләү.

Балаларда текст турында, беренчедән, мәгънә ягыннан үзара бәйләнгән һәм хәбәр итү интонациясе белән әйтелә торган, якынча тәмамланган фикерне белдерүче, билгеле бер эзлеклелектә килгән сүз һәм җөмләләр җыелмасы буларак, икенчедән, нәрсә турында да булса хәбәр итүче һәм ишетеп, күреп зиһенгә алына торган мәгълүмат буларак башлангыч күзаллау булдыру. Иллюстрация темасы буенча җөмләләр төзү. Конкрет җөмләләр белән текстның график моделе арасындагы мәнәсәбәтне ачыклау. Рәсем белән бирелгән хикәяне исемләү (исем кушу). Текст төзү элементлары. Тәкъдим ителгән график моделе буенча хикәя эчтәлеген сөйләү. Укылган текст эчтәлеге буенча бирелгән укытучы сорауларына җавап бирү. Текст эчтәлеген сайлап алып сөйләү, шигырь ятлау.

Телнең структур берәмлеге буларак сүз турында башлангыч күзаллау булдыру. Басма хәрефләрнең элемент-элгеләре белән танышу.

### Әлифба чоры

Сузык [а, ә, ы, э, и, у, ү, о, ө] авазларының сүздә төрле позициядә килгән һәм аерым кулланылган очрактагы артикуляцияләрен ныгыту. Сузык авазларны аеру күнегүләре. Иҗек ясау процессында сузыкларның роле. Сүз кисәге буларак иҗек турында белешмә. График схема буенча сузык авазны әйткәндә, сузыкка басым куеп әйтү. Сүзнең график схемалары буенча сүзне көйләп,иҗекләргә бүлеп салмак һәм орфоэпик дөрес уку. Сүзнең иҗекләргә бүленешен дуга ярдәмендә билгеләү.

Схемада сузык авазны башта түгәрәк, соңыннан транскрипция билгесе белән билгеләү. Ишетелгән һәм әйтелгән сүзләр арасыннан өйрәнелә торган аваз кергән сүзне таный һәм аера белергә өйрәнү. Өйрәнелгән сузык аваз кергән сүзләр сайлау.

Элемент-өлгә ярдәме белән басма хәрефләр төзү һәм аларның формаларын үзләштерү. Хәреф турында авазның тышкы билгесе, ягъни «киеме» буларак образлы күзаллау булдыру.Укытучы укыган текстны тыңлау, эчтәлеген аңлау, куелган сорауларга җавап табу, ишетеп кабул ителгән текстның эчтәлеген тулысынча яки сайлап сөйләү.

### Парсыз сонор тартык авазлар

[м, н, л, р, й, ң] сонор тартык авазлары. Бирелгән авазларның артикуляциясе : үпкәдән килә торган һава агымы бер сөйләм органында, мәсәлән иреннәрдә, тешләрдә, тел алдында, тел уртасында, тел артында киртәгә яки токтарлыкка очрый, бу авазларны әйткәндә тон өстенлек итә, шау катнаша гына. Шуңа күрә ул авазларны ярым сузыклар дип тә йөртәләр.

Калын һә̀м нечкә̀ яңгырашлы сүзлә̀рдә̀ сонор тартык авазлар ә̀йтелешен чагыштыру; язуда аларның калын яңгырашын калын сузык аваз хә̀рефлә̀ре (а, у, о, ы) белә̀н (ма, му), нечкә̀ яңгырашын нечкә̀ сузык аваз (ә̀, и, ө̀, ү, э) белә̀н белдерү. Сүздә̀ һә̀р авазны аерып ә̀йтү алымы. һә̀м схема белә̀н бирелгә̀н аваз анализы. Анализлана торган сүз составына ә̀аерым аваз артикуляциясе. Тартык авазларның яңгыраулыгын белдерүче билге — уртасында нокта булган квадрат белә̀н билгелә̀ү.

**Яңгырау һәм саңгырау парлары булган тартыклар**

Яңгырау һә̀м саңгырау тартыкларны калын һә̀м нечкә̀ яңгырашын билгелә̀ү: нечкә̀лек яңгырау, саңгырау ([д-т],[з-с],[г-к],[гъ-къ] һ.б.) парларның үзара мө̀нә̀сә̀бә̀тен ачыклау. Мә̀сә̀лә̀н бар-бар, бар-пар һ.б. Ө̀йрә̀нү тә̀ртибендә̀ басма хә̀реф формаларын үзлә̀штерү.

Авазларында аерма булган сүзлә̀рне, яңгырау һә̀м саңгырау тартык авазлардан башланган сүзлә̀рне ә̀йтеп карау, чагыштыру күнегүлә̀ре

**Аваз-хәреф схемалары нигезендә авазларны аеру, иҗекләр, сүзләр, текстлар уку.**

Башлангыч сүзне һә̀м сүзнең авазын алмаштыру яки аваз ө̀стә̀ү юлы белә̀н ясалган яңа сүзлә̀рне (бур-бура-буран), шулай ук ике яктан да бертө̀рле укыла торган (ана) сүзлә̀рне уку. Табышмаклар уку һә̀м аларның җавабын табу. Тизә̀йткечлә̀р, санамышлар, үртә̀вечлә̀р, ө̀йрә̀нелә̀ торган аваз булган халык мә̀кальлә̀рен уку, истә̀ калдыру һә̀м хә̀тер буенча сө̀йлә̀ү. Аваз. иҗек.сүз.җө̀млә̀ һә̀м текст турында образлы күзаллау формалаштыру.

Аеру билгелә̀ре булып торган ь һә̀м ъ тансоң [й] авазы

Язуда аеру билгелә̀ре булып торган ь һә̀м ъ һә̀м сузык аваз хә̀рефлә̀рә̀ ярдә̀мендә̀ [й] авазының язуда бирелешен (ь+е, я, ю; ъ+е, ю, я) аңлату. (Я, е, ю хә̀рефлә̀ре алдындагы иҗек калын сүзлә̀ргә̀ (алъяпкыч) ъ билгесе, алдагы иҗек нечкә̀ сүзлә̀ргә̀ (дө̀нья) ь билгесе куелуын аңлатыла).

Аеру билгелә̀ре һә̀м сузык аваз хә̀рефлә̀ре белә̀н белдерелгә̀н [й] авазлы сүзлә̀рнең аваз анализы. [Й] авазы кергә̀н сүзлә̀рнең аваз схемасын уку. аны хә̀реф формасына үзгә̀ртү, соңыннан башта иҗеклә̀п, аннан соң орфоэпик дө̀рес итеп уку. Ь, ъ билгелә̀ренең басма хә̀рефлә̀рен тө̀зү һә̀м аларның формаларын үзлә̀штерү. Парсыз тартык авазлар

Парсыз [х, һ, щ, ц] тартыклар артикуляциясе. Бу авазларның характеристикасы. Парсыз тартык авазлар кергә̀н иҗеклә̀р һә̀м сүзлә̀р, текстлар уку. Текстның эчтә̀леген үзлә̀штерү. Эчтә̀леген сө̀йлә̀ү. Басма хә̀рефлә̀рнең формаларын үзлә̀штерү.

**Әлифбадан соңгы чор. Татар халык авыз иҗаты белән танышу.**

Халык авыз иҗаты турында гомуми күзаллау. Авторларының булмавы, телдә̀н сө̀йлә̀м, гамә̀ли уен характерындагы кече жанр ә̀сә̀рлә̀ре. Бишек җырлары, санамыш, табышмак, тизә̀йткеч, эндә̀шлә̀р. Ә̀йлә̀нмә̀ле һә̀м чылбыр ә̀киятлә̀ре. Халык авыз иҗатының табышмак, ә̀йлә̀нмә̀ле ә̀кият кебек формаларын гамә̀ли үзлә̀штерү.

Сурә̀тлә̀нгә̀н вакыйгаларга карата автор фикере (ә̀сә̀р исеме, геройларга характеристика, автор бә̀ялә̀мә̀есе).Тө̀рле жанрдагы текстларны аңлап уку күнекмә̀лә̀рен формалаштыру. Текстагы «авыр» (озын һә̀м таныш булмаган) сүзлә̀рне укыганда иҗеклә̀п укырга мө̀мкин. Җө̀млә̀нең тыныш билгелә̀ренә̀ карап җө̀млә̀лә̀р арасында тукталыш (пауза) ясау. Хикә̀ялә̀ү, сорау, тойгылы җө̀млә̀лә̀рнең интонациясен бирү. Укылган текст буенча бирелгә̀н сорауларга тулы җавап бирү. сайлап алып эчтә̀леген сө̀йлә̀ү, текстның башын, ахырын үзгә̀ртү, аңа яңа исем бирә̀ белү күнекмә̀лә̀ренә̀ ия булу.Текстның 1) башлам (вакыйга нә̀рсә̀дә̀н башалана).

2) төп өлеш (катнашучы-геройлар белән нәрсә була), 3) йомгаклауга (нәрсә ничек тәгәлләнә) туры килә торган кисәкләрен табу һәм уку. Текста сурәтләнгән вакыйгаларга укучы баланың һәм авторның мөнәсәбәтен белдерә белү.

Тормыш-көнкүреш әкиятләре. Тормыш-көнкүреш әкиятләренең килеп чыгышы. Тылсымлы әкиятләрдән аермалы яклары. Әкиятләрдә проблемалар, үгет-нәсыйхәт, юмор хисе.

**Әдәби жанрлар**

Жанрлар турында гомуми күзаллау булдыру; хикәя, шигырь. Хәсән Туфан. ―Юкмыш бабай малае‖.

**Библиографик культура**

Дәреслектә җиңел генә ориентлашырга өйрәтү: эчтәлектән кирәкле әсәрне тиз генә эзләп таба белү. Кече яшьтәге мәктәп баласының дәрестән тыш эшчәнлеген оештыру: өй, мәктәп китапханәләреннән файдалану.Республика, туган як турында мәгълүмат бирү. Татар язучылары иҗаты белән танышу.

**Уку , сөйләү, тыңлау күнекмәләре формалаштыру. Автор әсәрләре.**

Укучыларны тиз һәм йөгерек укырга гадәтләндерү. Укыганда орфоэпия нормаларын төгәл саклау, дөрес тавыш төсмерләре (тавыш көче, темпы) белән укырга өйрәтү. Аңлап һәм сәнгатьле уку күнекмәләре булдыру. Укуга карата таләпләрне төгәл үтәү: кычкырып укуның дөреслеге, сәнгатьлелеге, укуның тизлеге. Резеда Вәлиева ―Кыңгырау чәчәк‖ хикәясе. Х. Халиков. ―Өлләүл да белә микән?‖, ―Песи үләне‖, ―Каен җиләге‖, ―Тузганак‖, ―Энҗе чәчәк‖.

**2 нче сыйныф**

**Халык авыз иҗаты**

**Әкиятләр**

Хайваннар турында әкиятләр. Әкиятләр турында гомуми күзаллау булдыру. Татар халык әкиятләрендәге төп герой белән башка халыклар әкиятләрендәге төп герой арасындагы охшаш һәм аермалы яклар. Геройларның характеры. Россия халыклары әкиятләре. Хайваннар турында әкиятләрнең, гасырлар кичеп, хәзерге көнгә кадәр килеп җитүе: бик борынгы әкиятләр, борынгы әкиятләр, әкияти вакыйгалар.

Әкиятләрнең тәрбияви роле. Геройларның характеры, аларның акыл-фигыльләре, һәрвакыт ярдәмчел, киң күңелле булуларына игътибар итү, ишарә ясау. Күчмә сюжетлар.

Тылсымлы әкиятләр. Сюжет куелышы. Җирдәге һәм тылсымлы дөньяны чагыштыру. Тылсымлы предметлар (эченнән гаскәр чыга торган таяк, төрле ашамлыклар тулы тырыс, хәзинәсе бер дә кимеми торган сумка, кеше күзенә күрсәтми торган бүрек, җилән, зур атлата торган итек, дошманны кырып сала торган кылыч һ.б.), герой куллана торган тылсымлы әйберләр: тарак,көзге, кайрак, балдак. Тылсымлы булышчылар (җенлекләр: әтәч, бүре, аю, куян, шулай ук убырлы карчык һ.б.), тылсымлы төсләр (ак һәм кара). Борынгы дөньяның тылсымлы әкиятләрдә чагылышы (табигать көчләре, кешеләрнең хайваннарга, үсемлекләргә әверелүе).

Тылсымлы әкиятләрнең төзелеше (вакыйгаларның чылбыр рәвешендә баруы, кабатланулар, билгеле бер ритм, әкиятне истә калдыру). Әкият геройларының тылсым дөньясында сәяхәт итүе, сынаулар аша үтүе, явыз көчләрне җиңүе, гаделлекнең тантана итүе. Дөнья халыклары әкиятләре.

―Батыр әтәч‖, ―Әтәч патша‖ ."Бүдәнә белән төлке‖. ―Аю белән төлке‖ ; ―Гөлчәчәк‖ , ―Өч кыз‖ татар халык әкиятләре.

**Мәкальләр.**
Мәкальләр – халыкның тормыш тәҗрибәсеннән тупланган акыллы сүзләр белән таныштыру. Мәкалләрнең мәгънәсен аңлату. Мәкальләрне төрле ситуацияләрдә урынлы куллана белергә күнектерү. Төрле халыкларның мәкальләре, аларның охшашлыгы. Әкият, мәсәл, хикәянең, иллюстрацияләрнең эчтәлегенә туры килә торган мәкальләрне дөрес сайлау. **Риваять.** Риваять турында гомуми күзаллау. ―Тавык нигә суда йөзә алмый?‖ риваяте Автор әкиятләре
Тылсымлы шигъри әкиятләр, аларда халык әкиятләре белән сюжет бәйләнеше, композиция үзенчәлеге. Автор әсәрләрендә һәм халык әкиятләрендәге сюжет кулланылышы (капма-каршы ике дөнья, булышчылыр, тылсымлы тәсләр). Автор әкиятләрендә, нәкъ халык әкиятләрендәгечә, вакыйгаларның кабатлануы, чылбыр рәвешендә тезелүе, аерым сүзләрнең ритмик кабатланып килүе. Автор теленең кабатланмас матурлыгы. Сәнгатьле уку, сүзлек эше, эчтәлек сөйләү, төп геройларга характеристика бирү.
Г.Тукай ―Су анасы‖, ―Кәҗә белән Сарык‖ әкиятләре; М. Гафури ―Тавык белән үрдәк‖ шигъри әкияте,Ш. Галиев ―Җизни әкияте‖, ―Ник соң әле итек җитмәде‖, Н. Исәнбәт ―Мырауҗан агай хәйләсе‖, Г. Вәлиева ―Су әкияте‖.
**Татар халык авыз иҗаты белән танышу.**
**Әдәби жанрлар**
**Шигърият**
Шигъри формада язылган әсәрләр (Р. Вәлиева, Ф. Яруллин, Җ. Дәрзаман ,Йолдыз). Йолдыз
―Белмим‖ Әсәр исеменең төп мәгънә, эчтәлек белән туры килүе. Р.Вәлиева ―Замана баласы‖ Эш эшкә өйрәтә. Ф.Яруллин ―Эшнең аның берние юк‖.
Җанлы сөйләмнең мөһим чаралары . Җ.Дәрзаман ―Солдат булдым‖.
Дөньяны шагыйрьләр күзлегеннән чыгып танып белү: шагыйрьнең матурлыкны тоя белергә өйрәтүе. Рифма белән танышу: аны сиземли, таба, куллана белергә күнектерү Кеше һәм табигать бергәлеге. Дөньяны шагыйрь күзлегеннән чыгып күзаллау. Әйләнә-тирә дөньяның матурлыгы — шагыйрь өчен илһам чишмәсе булуга инандыру. Шигырьдә чагыштыру, сынландыру, эпитет. Автор әсәрләрендә һәм халык авыз иҗатында охшашлык. Чагыштыру, контраст,җанландыру кебек гади әдәби алымнарны таба белү. Җанлы сөйләмнең мөһим чараларын үзләштерү күнегүләре: темп,тавыш көче, тон, сөйләм мелодикасы (тавышны күтәрү,түбәнәйтү).
Г.Тукай,Н.АхуноваА., Р Вәлиева,, Р.Файзуллин, Э.Шәрифуллина әсәрләре; Г.Тукай ―Буран‖; кыска шигырьләр;Н.Ахунова ―Хоккулар‖;Э.Шәрифуллина ―Алтын балык‖.Г.Морат, Г.Хәсәнов, Ә.Еники, Р.Мингалим, Йолдыз, Ф.Сафин, М.Фәйзуллина, Р.Газизов, С.Урайский, Л.Лерон, М.Галиев,М.Шабаев, Э.Шәрифуллина, Г.Мөхәммәтшин, Р.Вәлиева, Р.Корбан әсәрләре.
Әсәрләрне анализлый белү, рәссамнарның матурлыкны буяулар белән бирү үзенчәлекәрен белү, картиналардагы матурлыкны күрә белү, табигатьнең матурлыгын күрә белү.
**Хикәя.** Хикәянең исеме. Ике образны чагыштырып сөйли белү. Әсәр геройларына карата үз фикереңне белдерү. Жанр үзенчәлекләре: сурәтләнгән вакыйгаларның тормышчанлыгы; әхлакый проблемаларның актуальлеге; уйдырмалар. Хикәянең төп мәгънәсе. Хикәя исеменең эчтәлеккә туры килүе. Хикәя геройлары, аларның портретлары һәм характерларының сөйләмнәре, башкарган гамәлләре аша чагылышы. Авторның үз героена мөнәсәбәте. Хикәядә авторның үз геройларына мөнәсәбәте. Хикәя герое. Характер һәм тойгылар

үзенчәлеге. Геройларның характерына чагыштырма анализ. Авторның геройга, вакыйгаларга, күренешләргә мөнәсәбәтен сиземли алу, үз фикереңне әйтә белү.

Л. Лерон,, И.Туктар, Р. Миңнуллин әсәрләрен уку. Л.Лерон ―И ямьле дә соң дөнья!‖ .И.Туктар ―Урман букеты‖. Р.Миңнуллин ―Чыршы әйләнәсендә‖.Кеше һәм табигать бергәлеге. Дөньяны шагыйрь күзлегеннән чыгып күзаллау. Әйләнә-тирә дөньяның матурлыгы —шагыйрь өчен илһам чишмәсе булуга инандыру. Шигырьдә чагыштыру, сынландыру, эпитет. Автор әсәрләрендә һәм халык авыз иҗатында охшашлык. Чагыштыру, контраст,җанландыру кебек гади әдәби алымнарны таба белү. Җанлы сөйләмнең мөһим чараларын үзләштерү күнегүләре: темп,тавыш көче, тон, сөйләм мелодикасы (тавышны күтәрү,түбәнәйтү).

Р.Харис,Ш.Галиев,Ф.Садриев,Р.Миңнуллин,

Р.Сарби,Г.Юнысова,Г.Гыйльманов,Н.Арсланов,М.Әгъләмов,М.Шабаев,Н.Мадьяров,

З.Минһаҗева,Г.Шаһи,Ф.Зыятдинов, Р.Фәйзуллин, Г.Тукай,Р.Хафизова,Җ.Дәрзаман,Б.Рәхмәт,Р.Корбан,Л.Лерон,Ә.Моталлапов, Г.Афзал,Р.Вәлиева әсәрләрен уку.

Үзбәя бирә белү, табигатьне җанлы итеп күрә белү, табигатьнең кабатланмас кыйммәтен аңлый белү,дөньяга шигъри караш белән объектив караш арасындагы аерманы аера белү. гади генә предметлардан да тылсым күрә белү, бер тамчы суда да дөнья белән танышырга мөмкин икәнлеген аңлау, бинокль аша да дөнья белән танышырга мөмкин икәнлеген белү, матурлыкны ―Күңел күзе‖ белән күрә белү, күзәтүчән, игътибарлы һәм хыялый була белү, төрле ситуациядән чыгу өчен оптимистик карарлар кабул итү, тема һәм фикер уртаклыгын таба белү, авторның төп фикерен аңлый белү. Әсәр геройларының тирә-якка, дөньяга карашларын чагыштырып карау, бер предметка төрлечә караш, әсәрләрдәге вакыйга һәм күренешләрне капма-каршы кую алымы(контраст)Татар язучылары иҗаты белән танышу.

**Библиографик культура**

Газета-журналларның ни өчен вакытлы матбугат дип аталуын, яңалык белән гайбәт арасындагы аерманы аера белү. Яңалыклар ничек тарала? Балалар журналлары. Балалар газеталары . Татар телендә чыга торган балалар журналларын белү, журналларда һәм газеталарда ориентлаша белү.Татарстанда чыга торган балалар газета-журналлары белән танышу.

**Уку , сөйләү, тыңлау күнекмәләре формалаштыру**

Сәнгатьле уку күнекмәләре формалаштыру (интонация,тон, темп саклап кычкырып уку). Автор бирергә теләгән картинаны күзаллау. Эчтән укый белергә күнектерү. Чылбыр рәвешендә

укыганда, үз урыныңны белеп, чират буенча уку.Укылган әсәргә анализ ясау күнекмәләре. Юмористик һәм җитди характердагы әсәрләрне кычкырып, яттан укыганда эмоциональ характерын чагылдыру. Тавыш төсмерләре – интонация, тон, тавыш көче, темп, пауза, логик басым, сүзсез мимика, хәрәкәтләрне бирү күнекмәләре.

**3нче сыйныф**

**Әдәби жанрлар.**

Кеше һәм табигать бергәлеге. Дөньяны шагыйрь күзлегеннән чыгып күзаллау.

Әйләнә-тирә дөнья матурлыгының шагыйрь өчен илһам чишмәсе булуына инандыру. Шигырьдә чагыштыру, сынландыру, эпитет.

Автор әсәрләрендә һәм халык авыз иҗатында охшашлык. Чагыштыру, контраст, җанландыру кебек гади әдәби алымнарны таба белү.

Җанлы сөйләмнең мөһим чараларын үзләштерү күнегүләре: темп, тавыш көче, тон, сөйләм мелодикасы ( тавышны күтәрү, түбәнәйтү).Геройның эчке дөньясын аның әйләнә-тирә дөньяны танып белүе аша күрсәтү. Шагыйрьләр иҗат иткән дөнья белән чынбарлык арасындагы охшаш һәм аермалы якларны билгеләү. Шигырьләрне укыганда әдәби сурәтләү чараларын (чагыштыру, җанландыру, капма-каршылык, лексик һәм композицион кабатланулар) эзләп табу. Авторларның иҗат алымнары, тормышлары турында күзаллау булдыру. Диалогик һәм монологик сөйләмне үстерү. Әдәби әсәрләрнең башка сәнгать әсәрләре белән бәйләнеше Жанрлар турында гомуми күзаллау булдыру; хикәя, шигырь.Хикәянең исеме. Ике образны чагыштырып сөйли белү. Әсәр геройларына карата үз фикереңне белдерү. Жанр үзенчәлеге: сурәтләнгән вакыйгаларның тормышчанлыгы, әхлак кануннарына туры килүе, уйлап табучанлык. Әсәр исеменең төп мәгънә, эчтәлек белән туры килүе. Хикәя геройлары, аларның портреты һәм характер үзенчәлекләренең башкарган гамәлләре аша чагылышы. Авторның үз героена мөнәсәбәте. Хикәя герое. Характер һәм тойгылар үзенчәлеге.Геройларга чагыштырма характеристика. Хикәяләрдә автор билгеләмәсе: герой портреты, катнашучы геройларга характеристика, пейзаж һәм интерьер сурәтләнеше, геройны чолгап алган тирәлек. Әкият һәм хикәя жанрының аерымлыклары (бары тик күзәтелә генә): әкияттә кискен бирелә, ә хикәяләрдә композициянең уйланылмаган, алдан күрелмәгән борылыш алуы күзәтелә. Әкият һәм хикәя жанрының композиция үзенчәлеген ( күзәтүләр аша ) аңлату. Укучы- тыңлаучыга табигый көчләрнең серен, әкият геройларының серле тормыш агышын күрсәтү, хикәя геройларының характерында тормыштан алынган вакыйгаларны чагылдырып сөйләү.

Б. Рәхмәт ―Иң күңелле чак‖, Р. Хисмәтуллин «Июль аланы», Р. Вәлиева ―Җәй һәм бала‖, М. Галиев «Җиләктән кайтканда», М. Мирза ―Көздә бирмәл‖, ―Көз‖, ―Болыт‖, Б. Рәхимова «Шук болытлар, батыр җил, якты кояш», М. Гафури ―Болын‖, Н. Дәүли «Бала болыт», . Р. Корбан ―Көз нигә моңая‖, Р. Вәлиева ―Яңгыр, яу!‖, ―Китмә әле, бераз тор‖, Йолдыз ―Салават күпере‖, М. Әлимбаев ―Салават күпере‖, Л. Лерон «Яңгырның ял көне», М. Җәлил ―Яңгыр‖, Р. Мингалим «Август каеннары», Ш. Маннур ―Көзге урманда‖, З. Туфайлова «Яфрак ява», Х. Әюпов «Әбиләр чуагы», К. Тәхау ―Көзге урман‖, Р. Әхмәтҗан ―Соңгы яфрак‖, М. Мазунов «Карап торам», Г. Хәсәнов «Кыр казы», Г. Бәширов «Ана каз белән ата каз һәм аларны‖ унике бәбкәсе», Н. Гыйматдинова «Казлар», Г. Остер «Серне ачты», В. Хәйруллина ―Тәрбияче попугай‖, Н. Сладков ―Күзалдавычлар‖, Р. Әхмәт ―Сыкы‖, Н. Сладков ―Кем остарак‖, Р. Корбан ―Мәктәпкә озату бәйрәме‖, Г. Паушкин ―Кыш‖, Г. Рәхим ―Безнең тауда‖, Н. Әхмәдиев ―Чишмәгә суга барам‖, К. Кәримов ―Кышкы мәтрүшкәләр‖, Н. Гыйматдинова ―Сарбай‖, Л. Лерон ―Хыял‖, Йолдыз ―Антенналы бәрәңге‖, Л. Лерон ―Хыялый Акбай‖, Ә. Габиди ―Тере антенналар‖, Л. Лерон ―Мәче малае Шукбай‖, ―Шукбай балык тота‖, ―Хат‖, Ф. Мөслимова ―Хыялый‖, З. Гомәрова ―Хыялларым‖, Б. Рәхмәт ―Ничек өйрәнергә‖, Р. Фәйзуллин ―Тугайда‖, А. Әхмәтгалиева ―Болытта җиләк үсә‖, Ф. Садриев ―Юкка көттеләр‖, А. Гыйләҗев ―Суык‖, А. Аланазаров ―Дустымны эзлим‖, В. Хәйруллин ―Кем булам‖, Йолдыз ―Этем югалды бүген‖, Р. Гыйзәтуллин ―Батырлык‖, Г. Рәхим ―Иске самавыр торбасы‖, Р. Фәйзуллин ―Онытма син!‖, М. Мирза ―Идел-йорт‖, ―Без бабайсыз үстек‖, Р. Рәкыйпов ―Мин яратам сине, Татарстан!‖, Л. Шагыйрьҗан ―Сөембикә манарасы‖, В. Нуриев ―Хуҗалар тавы‖, Х. Туфан ―Казан‖, З. Гомәрова ―Батырлар хакында‖, Р. Харис ―Сугыш турында сөйләшә картлар‖, ―Игенче җыры‖, Г. Гыйлман ―Нәсел агачы‖, ―Дәү әтине‖, ―Универсиада‖, В. Хәйруллина ―Хозурлык һәм горурлык‖, Сугыш кайтавазы. Туган ил, Ватан турында хикәяләр уку. Ф. Кәрим ―Ант‖, ―Ватаным өчен‖, М. Җәлил ―Кичер, илем!‖, Х. Халиков ―Рәхмәт сезгә, ветераннар!‖, В. Нуруллин ―Бүреләр, үгез һәм без‖, С. Рәхмәтуллин ―Сандыктагы хәзинә‖, Р. Миңнан ―Без музейга барабыз‖, Г. Ахунов ―Канатлар кая илтә?‖, Г. Моратов ―Корыч

шулай чыныкты‖, И. Юзеев ―Матурлыкны гына алып кит‖, М. Рафиков ―Җир куены‖, Г. Бәширов ―Безнең Татарстан‖, Р. Фәйзуллин ―Нефть‖, ―Безнең КамАЗ‖, Йолдыз ―Спортчы Шүрәле‖, Р. Миңнуллин ―Кунакка килегез‖, Р. Вәлиев ―Барысын да яратам‖, Ш. Маннур ―Яратам‖, Р. Вәлиева ―Чыпчык‖, М. Хәсәеен ―Китап‖, С. Урайский ―Туган ил‖, А. Гыймадиев ―Шәмси маҗаралары‖, Н. Кәримова ―Авылым җыры‖, В. Нуриев ―Кем катырак суга?‖, Р. Вәлиева ―Яңгыр белән Кояш‖, Г. Сабитов ―Тәүге шатлык‖, Ә. Баянов ―Тургай‖, Н. Гыйматдинова ―Болын патшасы‖, А. Әхмәтгалиева ―Безнең чишмә‖, Г. Бәширов ―Беренче кар‖, Н. Сладков ―Кышкы җәй‖, М. Мазунов ―Яңа карлар ява‖, И. Солтан ―Кар ник шыгырдый?‖, И. Солтан ―Кар ник ява?‖, Р. Мәннан ―Кыш килә‖, Ф. Зыятдинов ―Муллык билгесе‖, М. Мирза ―Кышның китәсе килми‖, Р. Миңнуллин ―Кар бәйрәме‖, С. Урайский ―Кыш шатлыгы‖, Р. Вәлиева ―Каникул вакытында‖,

Ш. Галиев ―Иншаның файдасы‖, ―Сүзләре һәм үзләре‖, В. Нуриев «Инша», Л. Лерон «Иртән уянасынкилмәсә», Сүз тыңлыйсыз килмәсә, «Инша», Р. Вәлиева «Кәчле укучы», «Сыер эзләгәндә», К. Тәңрекулиев «Эшчән» , Гельды», И. Юзеев «Хатасыз ничек язарга?», Р. Миңнуллин «Хаталар өстендә эшләү», Г. Морат «Үскәч кем булырга», «Тиргиләр», Р. Низамова «Табигать күренеше», Р. Фәйзуллин «Ничек яхшы булырга?», Йолдыз «Ике җаваплы табышмак», Н. Кәримова «Кое чыпчыгы», З. Туфайлова «Трай», А. Алиш «Утлы йомырка», Р. Вәлиев «Минеке».

**Халык авыз иҗаты әсәрләре**

Халык авыз иҗатының бер төре булган һәм җир йөзендәге барлык милләтләрдә дә яшәп килүче, буыннан буыннарга күчеп йөри торган хайваннар турындагы әкиятләргә карата гомуми күзаллау булдыру. Әкиятләрнең гасыр дәвамында үсеше. Гади вакыт тасмасы:

1) бик борынгы әкиятләр, 2) борынгы, 3) бик борынгы булмаган әкияти вакыйгалар турында аңлату.

Бик борынгы әкиятләрдә хайваннар арасындагы мөнәсәбәтләр, аларның тышкы күренешләре төп урынны алып тора. Борынгы әкиятләрдә геройның аңы,хәйләгә осталыгына дан җырлана.

Әкияти вакыйгалар исә үз эченә геройның изге эшләрен, аның сәләтен, киң күңеллеген күрсәтүне максат итеп куя. Йөремсәк әкиятләр турында күзаллау булдыру.

Әфган халык әкияте: « Иң яхшы дару, «Табышны ничек бүләргә?», «Кабартма»; Уйгур халык әкияте: «Тылсымлы китмән»; Инглиз халык әкияте: «Кәрән тәстеге пингвин баласы»; Монгол халык әкияте: «Әтәч таңда нигә кычкыра?»; Манси халык әкияте: «Куянның колагы нигә озын?»; Кабарда халык әкияте: «Җенлекләр патшасы»; Венгр халык әкияте: «Комсызлык бәласы»; Африка негрлары әкияте: «Сырны ничек бүләннәр?»; Эстон халык әкияте: «Куянның ирене нигә ярык?»; Эвенк халык әкияте: «Әтәч нигә кычкыра?»; Казакъ халык әкияте: «Юмарт дәя»; Нугай халык әкияте: «Карт һәм су анасы»; Норвегия халык әкияте: «Кабартма»; Алман халык әкияте:

«Сандугач белән Аю»; Каракалпак халык әкияте: «Җәй белән Кыш нигә күрешми?»; Латыш халык әкияте: «Шайтанга ничә яшь?»; Литва халык әкияте: «Итагатьле мәче», Л. Лерон «Әкияти башламнар», Йолдыз «Охшашлык», Э. Шәрифуллина «Әкият кайда?»

**Автор әсәрләре**

Автор әкиятләрендә, нәкъ халык әкиятләрендәгечә, вакыйгаларның кабатлануы, чылбыр рәвешендә тезелүе, аерым сүзләрнең ритмик кабатланып килүе. Автор теленең кабатланмас матурлыгы.

Ф. Яруллин «Тылсымлы ачкыч», Р. Мингалим «Уйларга кирәк», Р. Харис «Берсе калсын иде», Р. Вәлиева «Кышкы ямь», Йолдыз «Белмәгәнен белми», М. Мирза «Язның тәүге көннәре», Г. Хәсәнов «Корташар», «Гөбләә», «Май», Ә. Рәшит «Яшенле яңгыр», Г. Гыйлман «Көзге урман», Ф. Садриев «Белемле әби», Х. Халиков «Витаминлы аш», Н. Гыйматдинова «Дару».

**Мәсәлләр**Мәсәлләрнең ике өлештән – сюжеттан һәм моральдән (үгет-нәсыйхәт, әдәп-әхлак кагыйдәләре) торуын аңлату. Мәсәлләрнең хайваннар турындагы әкиятләрдән килеп чыгышы һәм гасырлар дәвамында үсеше. Бөтен дөньяга танылган мәсәлчеләр: Эзоп, Ж.Лафонтен, И.Крылов, татар мәсәлчеләре К.Насыйри, Г.Тукай,М.Гафури, Г.Шамуков, Ә.Исхак һәм башка язучылар әсәрләрен өйрәнү. Төрле халык мәкальләре . Мәкальләрне сөйләмдә, мәсәлләрдә урынлы куллану. Дөньяны шагыйрьләр күзлегеннән чыгып тану. Мәсәл һәм әкиятне чагыштыру. Мәсәлләрнең хайваннар турындагы әкиятләрдән килеп чыгуы. Мәсәлләрнең төп асылы, эчтәлеге. Мәсәл моралендә мәкальләр куллану. Мәсәлләрнең тәрбияви роле. Татар язучыларының мәсәлләре белән танышу.

Эзоп «Давыл белән Кояш», Г. Тукай «Җил илә Кояш», Н. Исәнбәт «Ябалак белән Чыпчык», татар халык әкияте «Ябалак белән чыпчык», Ф. Яруллин «Мактану бәласе», К. Насыйри «Төлке белән Әтәч», М. Гафури «Маймүн белән күзлекләр», «Чикерткә белән кырмыска», Г. Тукай «Көзге белән маймыл2, Г. Шамуков Көзге белән Маймыл», Т. Яхин «Карга белән Төлке», Ф. Яхин «Сыр бәласе», Г. Шамуков «Карга белән Төлке», Ф. Яруллин «Хәйләкәр куян», М. Гафури «Ике белән бака», В. Гаршин «Ил гизүче бака», В. Радлов «Карганың бәласе», Л. Толстой «Зирәк Чәүкә», К. Насыйри «Комсыз эт», С. Шакир «Таш белән Кырмыска», Ә. Исхак «Карт Имән белән яшь егет», М. Гафури «Ике чебен», М. Саттар «Кырмыска белән тирес корты», Г. Тукай «Яшь агач», Г. Тукай «Төлке белән йөзем җимеше», Ә. Исхак «Төлке белән виноград», Г. Вәлиева «Заман әкияте», Г. Тукай «Аккош, Чуртан һәм Кыскыч», И. Крылов «Аккош, Чуртан һәм Кысла», М. Гафури «Кәҗә белән Төлке».

**Библиографик культура**

Дәреслектә җиңел генә ориентлашырга өйрәтү. «Эчтәлек» бите белән танышу, аңа карап, кирәкле әсәрне китаптан таба белү; кече яшьтәге мәктәп баласының дәрестән тыш эшчәнлеген оештыру: өй, мәктәп китапханәләреннән файдалану.Халыкның үткән тарихы, тарихи һәйкәлләре, тарихи шәхесләре белән танышу.

Фән буенча сүзлек, белешмә әдәбият, вакытлы матбугат белән эшләү. Балалар китабы белән эшләү. Китапның төп элементын аеру: китап тышлыгы, китап төпсәсе, битләре. Китапны саклап тоту күнекмәләре булдыру. Төрле җыентыклар төзергә өйрәнү. Тематик һәм монографик җыентыклар турында күзаллау булдыру. Төрле тематик җыентыклар төзү күнекмәләре бирү. «Сайланма әсәрләр» төшенчәсе бирү. Теге яки бу язучы, шагыйрь иҗатын өйрәнгәннән соң, аның әсәрләреннән нәни җыентыклар төзү. Китапханәләрдән файдалана белү осталыгын үстерү, тәкъдим ителгән исемлек буенча китаплар сайлый белергә өйрәтү.

**Уку, сөйләү, тыңлау күнекмәләре формалаштыру**

Сәнгатьле уку күнекмәләре формалаштыру (интонация, тон, темп саклап кычкырып уку). Автор бирергә теләгән картинаны күзаллау. Эчтән укый белергә күнектерү . Чылбыр рәвешендә укыганда, үз урыныңны белеп, чират буенча уку. Укылган әсәргә анализ ясау. Уку техникасын үстерү. Юмористик һәм җитди характердагы әсәрләрне кычкырып, яттан укыганда эмоциональ характерын чагылдыру. Тавыш төсмерләре – интонация, тон, тавыш көчә, темп, пауза, логик басым, сүзсез мимика, хәрәкәтләрне бирү күнекмәләре.

**4 нче сыйныф**

**Халык авыз иҗаты.**

**Мифлар турында гомуми күзаллау булдыру.**

Борынгы халыкларның тормышы, кеше һәм табигать арасындагы мөнәсәбәт. Тормыш агачы.

Тотем хайван һәм үсемлекләр, кешеләрнең аларга карашы, борынгы традицияләрнең сакланышы.

**Тылсымлы әкиятләр.**

Дөнья турында борынгы күзаллаулар чагылышы. Тылсымлы әкият герое. Тылсым дөньясы. Тылсымлы предметлар, сихри саннар, сүзләр, тылсымлы булышчылар, тылсымлы әкият законнары: әкият герое өеннән чыгып китә. Максатка ирешү юлы (тылсым дөньясы, карурманнар аша үтүче юл, сынаулар, тылсымлы булышчы ярдәме, җиңү шатлыгы.) Халык әкиятләренең мифлар, легендаларда чагылышы.

Риваять, бәет, мифларда кешеләр тормышының чагылышы, табигый көчләрнең кешеләргә ярдәмгә килүе. Кешелек дөньясы һәм тылсымлы дөнья арасындагы бәйләнеш.

Риваять һәм легендаларда сөйләнгән геройлар, аларның кичерешләре. Тарихи бәйләнеш. Төрле атамалар. Аларның килеп чыгышы.

Риваять һәм легендаларда бирелгән вакыйгаларның әкиятләрдә чагылышы.

**Автор әкиятләре.**

Халык әкиятләрендәге тылсым юлы белән җиңүләр, автор әкиятләрендә акыл белән эш итеп уңышка ирешү, ярату һәм яратыла белүнең көче.Автор һәм халык әкиятләрендә сюжет-композиция охшашлыгы, яңа мәгънәви тәсмерләр бирү. Татар, рус, дөнья классикасында халык әкиятләре һәм автор әкиятләрендә охшашлык: сихри көчләрне җиңү юллары (халык әкиятләрендә), ярату хисенең көче (автор әсәрләрендә).

**Фольклор жанрының тормышта, хәзерге вакытта яшәеше.**

Халык традицияләре һәм бәйрәмнәре. Символик төшенчәләр. Гимннар (Татарстан гимны). Халкыбызның гореф-гадәтләре белән тирәнтен таныштыру. Милли бәйрәмнәрнең тарихы белән таныштыру.

**Хикәя.**

Хикәя жанры турнда күзаллау формалаштыруны дәвам итү. Хикәя геройлары, аларның портреты һәм характер үзенчәлекләренең башкарган гамәлләре аша чагылышы. Авторның үз героена мөнәсәбәте. Геройларга чагыштырмача характеристика. Герой яшәгән тирәлек, пейзаж. Хикәядәге чынбарлык чагылышы. Әдәби тел бәремлекләре.Жанрларның максаты төрле булуга игътибар итү: әкиятләрдә укучы-тыңлаучыга табигатьнең югары көчләре тәэсире, геройларның халәте бирелсә, хикәяләрдә теге яки бу вакыйгада геройларның характерын ачу күзәтелү. Хикәя жанрының үзенчәлекле якларын күзәтү: а) хикәяләрдә вакыйгалар агышы (әсәр героеның характерын ачыклау өчен кызыклы хәлләр); ә) герой характерының катлаулылыгы; б) вакыйга һәм хәлләрнең киеренкелеге; в) әсәрнең сәнгатьле теле. Әсәрдә берничә сюжет сызыгы белән вакыйгалар бирелеше, геройларның кичерешләре, җиңүләре.

**Әкият һәм хикәя жанрының үзгәлеге турында күзаллау формалаштыру.**

Әкият һәм хикәя жанрларының композиция үзенчәлеген (күзәтүләр аша) аңлату. Укучы-тыңлауга табигый көчләрнең серен, әкият геройларының серле тормыш агышын күрсәтү, хикәя геройларының характерларында тормыштан алынган вакыйгаларны чагылдырып сөйләү.

**Шигърият**. Кеше һәм табигать бергәлеге. Дөньяны шагыйрь күзлегеннән чыгып күзаллау. Әйләнә-тирә дөнья матурлыгын шагыйрь өчен илһам чишмәсе булуын инандыру. Шагыйрьдә чагыштыру, сынландыру, эпитет.

Автор әсәрләрендә һәм халык авыз иҗатында охшашлык. Чагыштыру, контраст, җанландыру кебек гади әдәби алымнарны таба белү. Җанлы сөйләмнең мөһим чараларын үзләштерү күнегүләре: темп, тавыш көче, тон, сөйләм мелодикасы(тавышны күтәрү, түбәнәйтү). Лирик геройның («Катнашучы герой», «Автор») эчке дөньясын шигъри формада ачып бирү юллары: әйләнә-тирә табигатьне сурәтләү, хис һәм тойгылар чагылышы.. Тексттагы сүзләренең мәгънә төсмерләрен аера белү һәм аларны сөйләмдә куллану, сурәтләү чараларын тану һәм аңлау (чагыштыру, эпитет, метафора, фразеологик берәмлекләр, каршы кую, кабатлаулар)..Шигырьләрне укыганда әдәби сурәтләү чараларын (чагыштыру, җанландыру, капма-каршылык, лексик һәм композицион кабатланулар) эзләп табу Әсәр авторлары турында. Шагыйрь, язучы, рәссамның биографиясе. а) әсәрдә авторлар кичереше;

ә) автор күзәтүләренең чагылыш;

б) хәзерге заман авторлары белән очрашу, балаларның авторга сораулары, җаваплар.

**Библиографик культура формалаштыру.**

Эчтәлек бите белән танышу, аңа карап, кирәкле әсәрне китаптан таба белү, кече яштәге мәктәп баласының дәреслектән тыш эчтәлген оештыру: өй, мәктәп китапханәләреннән файдалану. Фән буенча сүзлек, белешмә әдәбият, вакытлы матбугат белән эшләү. Балалар китабы белән эшләү. Китапның төп өч элементын аеру: китап тышлыгы, китап төпсәсе, битләре. Китапны саклап тоту күнекмәләре булдыру. Төрле җыентыклар төзергә өйрәнү.Әдәби китапларда җиңел ориентлашу. Китап ахырында бирелгән эчтәлек белән эшләү. Китапның элементлары: титул бите, аннотация, китапның рәссам-бизәүчеләре турында өйрәнүне дәвам итү. Аерым әсәр яисә китапка аннотация яза белергә күнектерү. Сайланма әсәрләр турында белешмә бирү. Мәгънәсе аңлашылмаган яисә авыр язылышлы сүзләрне сүзлекләрдән таба белергә өйрәтү. Язучы, шагыйрьләр турында чыгышлар ясау.Төбәктә яшәүче язучылар, сәнгать кешеләре белән танышу.

**Уку, сөйләү, тыңлау күнекмәләре формалаштыру.**

Сәнгатьле уку күнекмәләре формалаштыру ( интонация, тон, темп саклап кычкырып уку). Автор бирергә теләгән картинаны күзаллау. Эчтән укый белергә күнектерү. Чылбыр рәвешендә укыганда, үз урыныңны белеп, чират буенча уку. Укылган әсәргә анализ ясау. Уку техникасын үстерү. Текстларны анализлаганда сәнгатьлелек чараларын табарга күнектерү. Сурәтләү чаралары турында беренчел күзаллау булдыру, кабатлауларның мәгънәсенә төшенү, тавышның сәнгатьлелеген ачыклау: рифма, ритм тою күнекмәләре.

**Укыла торган әсәрләр**

**Халык авыз иҗаты.**

«Җир ничек яралган?» (легенда), «Күкнең күтәрелүе (хикәят), «Айдархан һәм сәхабәләр, (легенда), «Пәйгамбәрнең тууы һәм аның балачагы», «Абага чәчәге (хикәят), «Ак бүре»(риваять), «Кырык кыз»( риваять), «Мәрҗан каласы һәм уникe кыз» (хикәят), «Дөнья

яратылу турында» (миф), «Хапи алла турында» (миф), «Чыршы ни өчен мәңге яшел?» (легенда) . Әкиятләр: «Ак байтал»,»Ак бүре», «Еланнар патшасы Шаһмара», «Үги кыз» , «Ике кыз», «Бумеранг»(Австралия халкы әкияте).

**Борынгы язучылар һәм татар әдәбияты классиклары** Кол Гали «Кыйссаи Йосыф».

Г. Тукай : «Таз», «Яз галәмәтләре».

Дәрдемәнд: «Гали».

З. Ярмәки: «Иртә», «Ак каен».

М.Җәлил: «Дару».

К.Насыйри. «Каз итен коймакка төреп,каймакка манып ашау».

Н.Исәнбәт: « Кышкы төндә», «Туган ил», «Өч матур сүз».

Ш.Бабич: « Тын төн», «Габдулла әфәнде Тукай». .

А. Алиш. «Сертотмас Үрдәк».

Г.Кутуй.» Яшен», «,»Рөстәм мажаралары».

Ш.Галиев:»Кол Галигә», «Алсу дөнья», «Җирдә миңа ни кирәк?», «Урман ява», «Тукран сые».

Г.Ибраһимов: « Укудан кайткач».

Г.Галиев.» Бибкәй аланы».

Ф.Әмирхан. « Кечкенә хезмәтче».

К.Нәҗми: «Нәсимәнең беренче эш көне».

З.Бәшири: « Бер асрауның аһ-зары».

Н.Думави: ««Беренче кар», «Ятим бала».

М.Мәһдиев: «Бәхилләшү».

С.Хәким: ««Яратам мин», «Тегермән стенасындагы язулар».

Ә.Фәйзи :»Асрарга бала бирәм».

Ф.Хөсни:»Малай белән солдат».

Ш.Рәкыйпов: « Төнге очыш».

И.Туктар: «Букет», «Бер каен үсә».

Г.Хөсәенов: « Аккош», «Абага».

Г.Сабитов: «Кадерле ул туган як!», «Чәчәк нигә боекты?».

Н.Арсланов: «Халкыма».

Ж.Тәржеманов: «Шуктуган», «Тукран малае Шуктуган».

Л.Ихсанова : « Шомырт чәчәкләре ак кына».

Ф.Яруллин: «Буар елан».

М.Әгъләмов: «Матурлык минем белән».

Зөлфәт: «Кыз тавы».

С.Шакир: « Ландыш чәчәге».
Р.Хафизова: «Кирлемән».
Г.Латыйп: «Минем нәсел».
Р.Гыйззәтуллин: «Язгы моң».
К.Тимбикова: «Бану әби сабагы».
К.Сибгатуллин: «Чыпчык», «Бөтен кеше бүген шундый әйбәт».
Роб.Әхмәтҗанов: «Безнең шигырь».
Р.Хисмәтуллин: «Аһ. Бер китсә кирәгә...»
**Рус язучылары:**
Л. Толстой «Слива төше».
Н. Сладков: «Тыштан ялтырый. _Эчтән  калтырый».
**Татар язучылары һәм шагыйрьләре (бүгенге көн язучылары)**
Р. Миңнуллин: «Иртән иртүк», «Атказанган сандугач», «Машина тавышлы көчек турында кечкенә әкият», «Сабантуйда», «Татарларым», «Минем телем», «Утыз Имәнине укыганда туган уйлар». Р. Фәйзуллин: «Быелгы яз», «Минем әти».

Х.Камалов: « Археолог».
Ә.Рәшит: « Нәсел агачы».
К.Булатова:»Кичә генә», «Шушы яктан, шушы туфрактан без».
Ж.Дәрзаман: «Бөҗәкләр белән сөйләшү».
Р. Вәлиева: «Изгеләр тавы», Энҗе чәчәк». «Бөтен дөнья ак кына», «Онытма!».
Р. Вәлиев: «Кошлар кайта», «Кайтчы, Сөембикә», «Эт кояшы» (өзек), «Ватаным».
Н. Әхмәдиев: «Хәерле иртә».
И.Гыйлаҗев: «Тутыкмас тотка», «Охшашлык».
Р.Харис: «Татарстан әлеме», «Зөләйха», Ак карлар арасында», «Елмай», «Туган җирем», «Фронтовиклар».
Л. Лерон: «Кыхмырый, Мыхмырый һәм Шыхмырый».
Э. Шәрифуллина» Табигатьнең бер бәртеге», Без татар балалары», «Тормыш яме».
Г. Гыйльманов: « Чишмәгә бардык», Кайтаваз», «Курай», «Җавапсыз легенда», «Минем исемем – Бүрек».
В. Нуриев: «Ачуланма инде. Илһам!»
Г. Рәхим:»Көз йөри», «Көзге моң», «Көзге урман», «Песнәк», «Апрель».
Р. Корбан: «Көз нигә моңлы?», «Ярдәм итик», «Курай».
Йолдыз: « Очрашу».
Р.Мингалим: « Бүген төнлә күккә кара».

Батулла: « Су иялӗре»(ӗкият), «Терек-терек кырмыска», «Салават күпере кайда йоклый?» В.Хӗйруллина « Хӗерле кӊн», «Алмаштыру»,»Наз», «Чикерткӗе». М.Мирза: « Кӊз», «Балачак хатирӗесе».
Ф.Бӗйрӗемова: «Кара пулат».
Мӊжӗеһит: «Бер яфрак зары».
Д.Гайнетдинова: «Исӗенме, яңа кӊн», «Батыр Хӗебир».
Л.Гыймадиева: «Кара урман, караңгы тӗен».
Н.Сӗейяр: « Айсылу».
Р.Рахман: « Кесӗел».
Н.Каштан: « ӗӨрем исе».
Г.Вӗелиева: «Кызыктырсалар да», «Карт алаша колагы».
Ф.Тарханова: «Без бӗелеш пешерӗебез», «Килде пилмӗен ашыйсы».
И Нӗебиуллина: «Тӗемле тел».
Ф. Мӗеҗитов: «Яңгыр кызы Гӊлтамчы».
Г.Мӊхӗеммӗетшин: « Туган як».
М.Галиев: « Туган як».
Г.Морат: « Чит тел».
С.Гаффарова: «Кӊз».
Р.Зӗейдулла: «Кол Гали‖.